ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 26.05.2023 | г. Иннополис | КАРАР 61

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 09.09.2021 ел, №96 карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү, элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел,№210-ФЗ Федераль закон, «Реклама турында» 13.03.2006 ел, №38-ФЗ Федераль закон нигезендә, шулай ук норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 09.09.2021 ел, №96 карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.10 бүлегенең исемен үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«2.10. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар һәм оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге».

1.2. 3 бүлекнең исемен үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлеш вакыты, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре. Бүлектә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары булырга тиеш, алар Гомуми билгеләр белән берләшкән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренә карата күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтү тәртибен үз эченә алырга тиеш».

2. Әлеге карар http://pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми порталында рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://verhniy-uslon.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче И.Р. Хуззятов